КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 ноябрь г.Казань № 1054

«Алабуга» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инвестиция программалары дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 ел, 25 декабрь, 1872 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуын унификацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының «Алабуга» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инвестиция программалары дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – дәүләт учреждениесе) бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы:

бу карарны кабул иткән көннән соң ике атна эчендә:

дәүләт учреждениесенең ликвидацияләү комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә дәүләт учреждениесен бетерү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

дәүләт учреждениесен бетерү турындагы карарны кабул иткәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен дәүләт учреждениесенең ябылу процессында булуы турындагы мәгълүматларны теркәүче органга кертергә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән бетерелә торган дәүләт учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле мөлкәтне алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

дәүләт учреждениесе бетерелү аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә, шулай ук дәүләт учреждениесен бетерү буенча законнар белән күздә тотылган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына ике ай эчендә Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан кертелгән тәкъдим нигезендә дәүләт учреждениесенә элегрәк беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен законнар белән билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына дәүләт учреждениесен бетерү буенча чараларны башлаганга кадәр, шартнамәнең барлык шартларын саклап, шартнамәнең яклары үзгәрүне күздә тотып, дәүләт учреждениесе тарафыннан инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән төзелгән шартнамәләргә тиешле төзәтмәләр кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин